Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Түбән Мактама бистә башкарма комитеты

# КАРАРЫ

13 июнь 2019 ел

№ 8

Күпфатарлы торак йортлар белән идарә итү, күпфатирлы биналарны тоту һәм ремонтлау буенча карарлар кабул итмәгән, муниципаль торак фонды биналарын шартнамә нигезендә һәм социаль наемга алучылар, 2019 елның икенче яртыеллыгы һәм 2020 елның беренче яртыеллгы өчен торак бинаны тоту һәм ремонтлауга түләү күләмен гомуми җыелышларда кабул итмәүчеләр өчен, муниципаль торак фонды биналарын шартнамә нигезендә һәм социаль наемга алучылар өчен торак бинаны тоту һәм ремонтлауга түләү күләме турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 ел 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Торак кодексының 156 һәм 158 маддәләре, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 ел 13 августындагы №491 "Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләре, хезмәтләр күрсәтү, эшләр башкару очрагында күпфатирлы йортта гомуми милекне тиешле сыйфатта һәм (яисә) билгеләнгән вакыт аралыгында карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында" гы карары нигезендә,

Түбән Мактама бистә башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1.Күпфатарлы торак йортлар белән идарә итү, күпфатирлы биналарны тоту һәм ремонтлау буенча карарлар кабул итмәгән, муниципаль торак фонды биналарын шартнамә нигезендә һәм социаль наемга алучылар, торак бинаны тоту һәм ремонтлауга түләү күләмен гомуми җыелышларда кабул итмәүчеләр өчен, муниципаль торак фонды биналарын шартнамә нигезендә һәм социаль наемга алучылар өчен торак бинаны тоту һәм ремонтлауга түләү күләмен расларга һәм халык өчен 2019 елның 01 июленнән 2020 елның 30 июненә кадәр гамәлгә кертергә. (Кушымта №1).

2. Әлеге карарны Түбән Мактама бистәсе һәм Тихоновка авыллары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда халыкка игълан итәргә, "Альметьевский вестник" газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

3. Әлеге карар 2019 елның 1 июленнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Түбән Мактама бистәсе җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе

Г.Р.Нәфыйкова

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Түбән Мактама бистә башкарма
комитетының 13 июнь 2019ел №8
карары белән расланган

Халык өчен күпфатарлы торак йортлар белән идарә итү, күпфатирлы биналарны тоту һәм ремонтлау буенча карарлар кабул итмәгән, муниципаль торак фонды биналарын шартнамә нигезендә һәм социаль наемга алучылар, торак бинаны тоту һәм ремонтлауга түләү күләмен гомуми җыелышларда кабул итмәүчеләр өчен, муниципаль торак фонды биналарын шартнамә нигезендә һәм социаль наемга алучылар өчен торак бинаны тоту һәм ремонтлауга 2019 елның 01 июленнән 2020 елның 30 июненә кадәр

## ТҮЛӘҮ КҮЛӘМЕ

| № п/п | Хезмәт күрсәтү исеме | Үлчәү берәмлеге | Айлык тариф |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Торак фонды белән идарә итү | руб./м$^2$ | 1,70 |
| 2. | Йорт эчендәге гомуми файдаланудагы урыннарны җыештыру | руб./м$^2$ | 1,56 |
| 3. | Йорт яны территориясен җыештыру | руб./м$^2$ | 2,22 |
| 4. | Торак биналарны агымдагы ремонтлау һәм йортяны территориясен автомат рәвештә ябыла торган җайланмалардан башка тәртипкә китерү | руб./м$^2$ | 2,33 |
| 5. | Торак биналарны агымдагы ремонтлау һәм автомат рәвештә ябыла торган җайланмалар белән (күпфатирлы йортта гомумимилек составында булган очракта) ремонтлау | руб./м$^2$ | 2,72 |
| 6. | Торак йортлар эчендәге су үткәргеч һәм канализация инженерлык челтәрләре системасына техник хезмәт күрсәтү, салкын су белән тәэмин итү приборларында исәпкә кертеп | руб./м$^2$ | 2,18 |
| 7. | Торак йортлар эчендәге су үткәргеч һәм канализация инженерлык челтәрләре системасына техник хезмәт күрсәтү салкын су белән тәэмин итү приборларыннан башка | руб./м$^2$ | 1,99 |
| 8. | Газ белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау һәм карап тоту | руб./м$^2$ | 0,20 |
| 9. | Электр белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау һәм карап тору | руб./м$^2$ | 0,82 |
| 10. | Торак биналарны капиталь ремонтлау | руб./м$^2$ | 5,85 |
| 11. | Дератизация | руб./м$^2$ | 0,15 |
| 12. | Торак урыннарны наемга (яллаучылар өчен) | руб./м$^2$ | 5,85 |

Түбән Мактама бистә башкарма
комитеты җитәкчесе Г.Р.Нәфыйкова